2023 елда Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы “Түбән Мактама шәһәр  тибындагы бистәсе”  муниципаль берәмлеге Түбән Мактама шәһәр  тибындагы бистәсендә гражданнарның үзара салымын кертү турында

ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ  КАРАРЫ

28 ноябрь 2022  ел № 2

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы “Түбән Мактама шәһәр  тибындагы бистәсе”  муниципаль берәмлеге Түбән Мактама шәһәр  тибындагы бистәсендә гражданнар җыены карар кабул итте:

1. 2023 елда Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы “Түбән Мактама шәһәр  тибындагы бистәсе”  муниципаль берәмлеге Түбән Мактама шәһәр  тибындагы бистәсе территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәм даими яшәүче һәр балигъ булган яшәүчедән (1 төркем инвалидларыннан, балачак инвалидларыннан, Бөек Ватан сугышы ветераннарыннан һәм аларга тиңләштерелгәннәрдән, бөек Ватан сугышында катнашучыларның толларыннан, сугыш хәрәкәтләре ветераннарыннан, мобилизация буенча чакырылган гаиләләрдән) 400 сум күләмендә үзара салым кертергә.

2. Алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтергә: юлларны,тротуарларны, урам утларын, балалар һәм спорт мәйданчыкларын норматив хәлгә китерү, Бөек Ватан сугышында һәлак булганнарның һәйкәлләрен ремонтлау һәм төзекләндерү, зиратларны төзекләндерү, трактор сатып алу, сметалар төзү, техник күзәтчелек үткәрү һәм җирлек милкенә рәсмиләштерү өчен түләү.

3. Әлеге карарны «Альметьевский вестник» газетасында бастырып чыгарырга, Түбән Мактама шәһәр  тибындагы бистәсе территориясендә урнашкан махсус мәгълүмат стендында урнаштыру юлы белән халыкка игълан итәргә, «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында» (PRAVO.TATARSTAN.RU) һәм кабул ителгәннән соң 10 көн эчендә Әлмәт муниципаль районы сайтында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштырырга.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Түбән Мактама бистә башлыгы Р.А. Бәдретдинов